**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «24» апреленнән № 103

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенең Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы һөнәри квалификация төркеме педагогик хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәсен раслау хакында» 2022 елның 14 апрелендәге 118 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенең Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы һөнәри квалификация төркеме педагогик хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2006 елның 22 февралендәге 15-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына мәгариф өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы Татарстан Республикасы законының 6 статьясындагы икенче өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2025 елның 07 апрелендәге под-1950/24 номерлы «2022 елның 29 мартындагы под-583/22 номерлы «Белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник яктан тәэмин итү өчен тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча методик тәкъдимнәр турында»гы әмергә үзгәрешләр кертү турында»гы әмерен гамәлгә ашыру йөзеннән, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенең Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы һөнәри квалификация төркеме педагогик хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәсен раслау хакында» 2022 елның 14 апрелендәге 118 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенең Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-техник тәэмин итү буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы һөнәри квалификация төркеме педагогик хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (2024 елның 16 октябрендәге 260 номерлы, 2024 елның 09 декабрендәге 301 номерлы, 2024 елның 18 декабрендәге 319 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлектә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль учреждениесенең мәгълүмати-методик бүлеге хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазифа атамасы | Айга төп оклад күләме, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | төп гомуми белем, урта гомуми белем | квалификацияле эшчеләр (хезмәткәрләр) әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, урта звено белгечләрен әзерләү программалары буенча урта һөнәри белем, тулы булмаган югары белем | аттестацияне уңышлы узган затка «бакалавр», «магистр» яки «дипломлы белгеч» квалификацияләрен бирү белән расланган югары һөнәри белем |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Методист | - | - | 22271,0 |
| | | | | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән методист | - | - | 22276,0 |
| | | | | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазифаларының һөнәри-квалификация төркеме | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик яктан тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлекнең структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы) урынбасары;<br><br>Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы педагогик мәгариф хезмәткәрләренең һөнәри квалификация төркеменең белем бирү эшчәнлеген методик һәм мәгълүмати-технологик яктан тәэмин итү буенча тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүлекнең структур бүлекчәсе мөдире (башлыгы); | - | - | 22362,0<br><br>22446,0». |

2. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http//novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов